**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«19» ноябрь 2024 ел №79

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында " 2019 елның 15 ноябрендәге 102 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советының 15.11.2019 ел, №102 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Советы тарафыннан 21.02.2020 ел, № 112, 03.09.2020 № 121, 08.12.2023 № 66, 26.03.2024 №72 үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) 1нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 13 статьясындагы 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт (муниципаль) контрактлары дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар план-графигы нигезендә, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган (Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый план-графикка кертелүгә тиешле сатып алулар булмаган очраклардан тыш) төзелә.), һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә түләнәләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш.»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге Советы рәисе Р.Г. Хисамов